КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 июнь г.Казань № 437

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны уртаклашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе турында» 2011 ел, 29 июнь, 530 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны уртаклашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны уртаклашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе турында» 2011 ел, 29 июнь, 530 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 25 февраль, 163 нче, 2014 ел, 16 май, 323 нче, 2014 ел, 22 август, 606 нчы, 2016 ел, 25 октябрь,

777 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны уртаклашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекчәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк дәрәҗәсендә - Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең кризислы хәлләрдә идарә итү үзәге (алга таба - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе КХИҮ), мәгълүмат үзәкләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының кизү-диспетчерлык хезмәтләре, «Росатом» атом энергетикасы буенча дәүләт корпорациясе (килешү буенча) һәм «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе (килешү буенча);»;

10 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гадәттән тыш хәлнең килеп чыгу куркынычы һәм факты турындагы мәгълүмат Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат бирү сроклары һәм рәвешләре турындагы күрсәтмәне раслау турында» 2021 елның 11 гыйнварындагы 2 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә тапшырыла».

Татарстан Республикасы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәгълүмат министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан вәкиллекләре тарафыннан әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә тапшырыла.

Җыелган һәм эшкәртелгән мәгълүмат нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар үз эшчәнлекләре өлкәсендә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат базасын формалаштыралар, аларны актуальләштерәләр һәм мәгълүмат базалары структурасы һәм аларның форматы турында мәгълүматны Россия ГТХМ мәгълүматлар базасына тапшыралар.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 8 июнь, 437 нче карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан министрлыкларга, ведомстволарга һәм оешмаларга һәлакәтләр һәм гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә хәбәр итү тәртибе

| Т/с | Министрлык, ведомство, оешма исемнәре | Оператив дежур, диспетчерлар телефоннары | Һәлакәтләр һәм гадәттән тыш хәлләр | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Автотранспорттагы һәлакәтләр (эре юл-транспорт һәлакәтләре) | Федераль трассаларда һәлакәтләр (ГТХ)[1] | Тимер юл транспортында, метрополитен объектларында һәлакәтләр (ГТХ) | Су транспортындагы һәлакәтләр (ГТХ) | Авиатранспортта һәлакәтләр (ГТХ) | Урман янгыннары | Куркыныч йөк төягән транспортта булган һәлакәтләр | Газүткәргечләрдә һәлакәтләр (ГТХ) | Нефть үткәргечләрдә һәлакәтләр (ГТХ) | АХОВ чыгару белән бәйле һәлакәтләр (ГТХ) | Биологик куркыныч характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Энергосистемаларда һәлакәтләр (ГТХ) | ТКХ объектларында һәлакәтләр (ГТХ) | Куркыныч геологик күренешләр | Радиоактив элементлы һәлакәтләр (ГТХ) | Авыл хуҗалыгы объектларында һәлакәтләр (ГТХ) | Гидротехник корылмаларда һәлакәтләр (ГТХ) | Рудникларда, шахталарда, мәгарәләрдә һ.б. һәлакәтләр (ГТХ) | Социаль әһәмиятле объектларда һәлакәтләр (ГТХ) | ПОО, ПВОО дагы һәлакәтләр (ГТХ) | Гидрометеорология һәм башка күренешләр | Эпидемиологик характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Экологик характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Социаль-икътисадый характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Шартлагыч матдәләр, шартлаткыч җайланмалар, сугыш кирәк-яраклары табу | Кешеләрнең исле (табигый) газ белән агулануы | Террорчылык акты |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
| 1. | Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор | 264-25-52, 9600-48-48-48 | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |
| «2. | Татарстан Республикасы Президенты иминлек хезмәте | 567-89-02, 567-89-04 | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |

[1]Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 10 нчы биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 264-77-01, e-mail: p.v@tatar.ru | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |
| «4. | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы | 292-05-87, 291-35-28 (кизү бүлеге) | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |
| «5. | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе | 221-74-21 | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |
| 6. | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 231-45-55, 292-18-33 | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |  | + | + |  | + | + | + | + | + | + |
| 7. | Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел буе федераль округы буенча транспорт иминлеген тәэмин итүгә дәүләт авиация күзәтчелеге идарәсенең Татар дәүләт авиация күзәтчелеге территориаль бүлеге | 510-99-19, 89872966176, 89061125600 | + | + | + | + | + |  | + |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  | + |  |  |  |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 293-12-23, 291-84-65 | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |  | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |
| 9. | «Татарстан Республикасының геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» ДУП | 277-82-97 |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  | + |  |  |  | + |  |  |  |  |  | + | + |  | + |
| 10. | Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 221-38-07, 292-18-46 |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  | + | + |  | + |
| 11. | «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» ФДУ | 273-54-08, 273-52-11 (факс) | + | + | + |  |  |  | + |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  | + | + |  | + |
| 12. | «Федераль юл агентлыгының «Самара - Уфа - Чиләбе» автомобиль магистрале идарәсе» ФДУ | (8347) 228-12-18, 228-12-14 | + | + |  |  |  |  | + |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  | + | + |  | + |
| 13. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгы | 229-85-92 | + | + | + |  | + | + | + |  |  | + | + |  | + |  | + |  |  |  |  |  |  | + | + | + | + |  | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14. | Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәтенең Идел буе идарәсе | 231-17-77 | | | | | | | +* | + | + | | | + | + | + | | + | + | + | + | | | | +** | + | + | | + |
| 15. | Татарстан Республика-сы буенча җир асты байлыкла-рыннан файдалану идарәсе | 277-00-85, 277-13-89 (факс) | | | | | | | | | | | | | | + | | | | + | | | | | | + | | | |
| 16. | Горький тимер юлы - «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы | 8 (831) 248-49-01 | + | | + | | | + | + | | | + | + | | | + | + | | | | | | | | | + | + | | + |
| 17. | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе | 277-12-33 | | | + | + | + | + | + | + | + | + | | | + | + | | | + | + | | | + | | | + | + | | + |
| 18. | «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» ФДУнең Татарстан Республика-сы филиалы | 277-82-09, 277-82-09 (факс) | | | | | | | | | | | | | | | | + | | | | | | + | | + | + | | + |
| 19. | «Средволгав одхоз» су хуҗалыгы ФДУ | 273-77-82 | | | | + | | | + | | | | + | | | + | + | | | | | | | | | + | + | | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 20. | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 570-18-99, 570-20-08 (кабул иту) | | | | | | | | | | | | | | + | | + | | | | | + | | + | + | + | | + |
| 21. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 238-98-54, 238-21-74, 298-93-08 | | | | | | | | | | + | + | | | + | + | + | | | + | | | + | + | + | + | + | + |
| 22. | Су юлларының һәм суднолар йөрешенең Казан районы - «Идел буе су юллары һәм суднолар йөреше дәүләт бассейн идарәсе» ФДУ филиалы | 231-05-54, 231-04-58 | | | | + | | | + | | | | + | | | + | + | | | | | | | | | + | | | |
| 23. | Россия Федерациясе Федераль саклау хезмәтенең Татарстан Республикасында махсус элемтә һәм мәгълүмат үзәге | 279-20-52, 277-58-08 (факс) | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Самара саклау отрядының Казан бүлеге - «Газпром» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы | 8 (846) 3101528 | | | | | | + | | + | + | + | | + | + | | | | | | | + | | | | + | | | |
| 25. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 231-14-10, 231-15-55 (факс) | | | | | | | | | | + | + | + | + | + | + | | + | + | | + | + | | | + | + | + | + |
| 26. | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 299-10-07, 292-00-21 | | | | | | | | | | | + | | | + | + | | | | | + | + | + | + | + | + | + | + |
| 27. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 293-40-72 (факс) | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |
| 28. | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 221-19-08, 264-34-52 | | | | | | + | | | | + | + | + | | + | + | | | | | + | + | | | + | + | + | + |
| 29. | 4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | 291-04-01, 291-04-38 | | | | | | | + | + | + | + | + | | | + | + | + | + | + | | | + | | + | + | + | + | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 30. | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 291-91-91 | + | + | + | + | + | | + | | | | | | | | + | | | | | | | | | + | + | + | + |
| 31. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 221-76-12, 221-76-31 | | | | | | + | | | | | + | + | | + | | + | | | | | | | | + | + | + | + |
| 32. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 292-92-12, 292-44-80 (факс) | | | | | | | | | | | | + | + | + | | | | | + | | | + | + | + | + | + | + |
| 33. | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 221-37-01, 221-37-37 (факс) | | | | | | + | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | + | + | + |
| 34. | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 264-37-45, 264-79-06 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | | + | |
| 35. | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 264-74-01 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | | + | |
| 36. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | 292-03-82, 221-77-47 | | | | | | | | | | | + | | | + | | | | | | | + | + | + | + | | + | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37. | "Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе" ДУ | 562-23-16, 562-23-18 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | | | | | | |
| 38. | «Татнефтепродукт» холдинг компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 292-43-03 | | | | | | | | + | + | + | | + | | | | | | | | | | | | + | + | | + |
| 39. | «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте | 200-01-52, 200-01-72 | | | | | | | | | | | | + | + | | | | | | | | | | | + | + | + | + |
| 40. | «Газпром Трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 272-65-34 | | | | | | | | + | + | + | | + | + | | | | | | | | | | | + | + | + | + |
| 41. | Татарстан таможнясы | 291-92-27 | | + | + | + | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | + | | + |
| 42. | «Казан» халыкара аэропорты» ачык акционерлык җәмгыяте | 267-87-48 | | | | | + | | | | | | | | | + | + | | | | | | | | | + | + | | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 43. | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе | 236-91-44 (эш вакытында), 236-97-64 (ял көннәрендә һәм эш көне булмаган вакытта), 296-36-00 (башлык) e-mail: Sergey.Kraynov@tatar.ru | | | | | | | | | | | | | + | | | | | | | | | | | | | + | |
| 44. | «Федераль экология операторы» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Идел буе территориаль округы» филиалының Казан бүлеге | 278-75-16, 278-75-36 | | | | | | | | | | + | + | + | | | | | | | | | | | | | + | | + |
| 45. | «БЕГИШЕВО» аэропорты» акционерлык җәмгыяте | 7(8552)79-67-15, 79-68-13 | | | | | + | | | | | + | | + | | + | + | | | | | | + | | | + | | | + |
| 46. | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 231-44-11 | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + | + |

Искәрмә. Һәлакат яки гадәттән тыш хәл турында мәгълүмат алганда (һәлакат, гадәттән тыш хәл характерына бәйле рәвештә) Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Кризис ситуацияләрендә идарә итү

үзәгенең оператив-дежур сменасы Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә, кызыксынган министрлыкларга, ведомстволарга һәм оешмаларга 20 минут эчендә хәбәр итәчәк.

*Куркыныч җитештерү объекты чикләрендә.

* *Куркыныч җитештерү объекты төзелеше барышында.

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

АХОВ - авария куркынычы булган химик матдәләр;
ДУ - дәүләт учреждениесе;
ДУП - дәүләт унитар предприятиесе;
ТКХ – торак-коммуналь хуҗалык;
ПВОО - янгын-шартлау куркынычы булган объектлар;
ПКУ - потенциаль куркыныч объектлар;
ФДУ - федераль дәүләт учреждениесе;
ГТХ - гадәттән тыш хәл.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 8 июнь, 437 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә докладлар регламенты

| Т/с | Мәгълүмат эчтәлеге | Кем тәкъдим итә | Кая (кемгә) тәкъдим итә | Мәгълүмат тапшыру срогы һәм дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә булган гадәттән тыш хәлләрне анализлау белән хисап | Татарстан Республикасы ГТХМ* | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ЦУКС ФКУ ОДС | узган ай өчен ай саен беренче числосына |
| «2. | Ведомство карамагындагы объектларда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне анализлау | потенциаль куркыныч объектлар булган министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар - техноген гадәттән тыш хәлләр буенча | 1. Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларына, ведомстволарына һәм оешмаларына.<br>Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ЦУКС ОДС.<br>3. Татарстан Республикасы КЧСында.<br>4. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында | ел саен узган елның 10 гыйнварына<br><br>ел саен узган елның 1 гыйнварына |
| 3. | Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча планлаштырылган чаралар турында | потенциаль куркыныч объектлар булган министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар - техноген гадәттән тыш хәлләр буенча | 1. Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларына, ведомстволарына һәм оешмаларына.<br>2. Татарстан Республикасы буенча Русия ГТХМ ЦУКС. | киләсе елның 1 декабренә ел саен |
| | | Татарстан Республикасы дәүләт | 1. Татарстан Республикасы | ел саен киләсе елга 15 декабрьгә |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 2 нче биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | хакимияте органнары - табигать, эпидемиологик һәм социаль-икътисадый гадәттән тыш хәлләр турында | КЧСында.<br>2. Татарстан Республикасы буенча Русия ГТХМ ЦУКС.<br>3. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында.<br>4. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында | |
| 4. | РСЧС функциональ ярдәмче системасы, РСЧС территориаль өстәмә системасы көчләре, чаралары һәм эше турында | федераль башкарма хакимият органнары һәм вәкаләтле оешмалар төзи торган РСЧС функциональ ярдәмче системалары, РСЧС территориаль ярдәмче системасының идарә органнары | 1. Татарстан Республикасы КЧСында.<br>2. Татарстан Республикасы буенча Русия ГТХМ ЦУКС. | ел саен узган елның 1 гыйнварына |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ГТХК - гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе;

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы – Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы;

Россия ГХМ – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы;

Татарстан Республикасы буенча Россия ОДС ЦУКС ГУ МЧС - Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең кризислы хәлләрдә идарә итү үзәгенең оператив-кизү сменасы;

РСЧС - гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы;

ЦУКС - кризис хәлләрендә идарә үзәге.